ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «__» апреленнән № ____

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2022 елның 18 гыйнварындагы 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 21 февралендәге 12-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2022 елның 18 гыйнварындагы 16 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибендә 4.6 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр кечерәк сроклар муниципаль маршруты буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны, муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукы бирелгән юридик зат, шәхси эшмәкәр яки гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы белән килештерелмәгән булса, мондый хокукның гамәлдә булу срогы дәвамында тиешле маршрутны аны билгеләгән Татарстан Республикасы Башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы инициативасы белән үзгәртү йә туктату турында карар мондый хокукның гамәлдә булу срогы тәмамланган көнгә кадәр 180 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә һәм мондый хокукның гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң үз көченә керә.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов